Республика Татарстан
Глава Енабердинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423643, Менделеевский район, д. Енабердино,
ул. Новая, д 10а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге Башлыгы

423643, Менделеевск районы, Енабердино авылы,
Яна урамы, 10а

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Enbrd.Men@tatar.ru,
http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/enaberdinskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01 ноябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Енабердино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 14 ноябре 17.00 сәг. ТР, Менделеевск муниципаль районы, Туйма торак пункты, Вахитов урамы, 40А йортында урнашкан Туйма авыл мәдәният йорты бинасында Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

“2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан 500 сум күләмендә, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Туйма авылында юлларны кардан чистарту);
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-81 тракторы өчен арба сатып алу, сәхнә урнаштыру);
«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Енабердино авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге башлыгы ____________ Е.Ю.Скворцова